**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шланга авылында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**22 нче ноябрь 2023 ел** **Шланга авылы** **№1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Шланга авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Шланга авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы 10.10.2019 ел, № 44/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2023 елның 22 ноябрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2022 елның 22 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы **469** кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**257**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **54,80 %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **252** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **98,05 %** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде, бу **1.95 %** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2023 елның 22 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шланга авылында 2023 елның 22 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау”.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт яки аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2)  махсус хәрби операциядә катнашучылар;

3) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары(хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр);

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары(хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр);

5) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүче)хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларының (ире (хатыны), балигъ булмаган балалары белән);

7) 1 группа инвалидлар;

8) 90 яшьтән узган халык

5. Әлеге карарны,  Ленин урамы  22 а йортында Шланга авыл мәдәният йорты, Ленин урамы  бина 22 Б адресы буенча урнашкан Шланга авыл җирлегебашкарма комитетының административ бинасында махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль

Шланга авыл җирлеге башлыгы,

халык җыенында рәислек итүче: И.И.Якупов